ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.08.2019 ел Баулы шәһәре №228

Баулы муниципаль районында мәҗбүри эш терләрен һәм җазага тартылган затлар мәҗбүри һәм тезәтү эшләре рәвешендә җәза үтә торган оешмалар исемлеген билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Җинаять кодексының 49нчы, 50нче статьялары, Россия Федерациясе Җинаять үтәтү кодексының 25нче, 39нчы статьялары нигезендә, административ һәм җинаять җәзасы билгеләнгән затларны төзәтү, җәмгыять нормаларына, кагыйдәләренә, иҗтимагый файдалы хезмәткә ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштыру максатларында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Билгеләргә:

1нче кушымта нигезендә Баулы муниципаль районы территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә административ һәм җинаять җазасын үтәтү урыннары исемлеген;

2нче кушымта нигезендә Баулы муниципаль районы территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә административ һәм җинаять җаваплылыгын үтәү өчен мәҗбүри эш төрләрен.

3нче кушымта нигезендә Баулы муниципаль районы территориясендә төзәтү эшләре рәвешендә җинаять җәзасын үтәү урыннары исемлеген.

2. Мәҗбүри һәм төзәтү эшләре рәвешендә җәза билгеләнгән затларга җәза үтәү урыннарын түбәндәгечә билгеләргә – «Баулы шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУда рәсми теркәлгән вакансияләр булганда, хуҗалык эшчәнлеген алып баручы барлык милек формасындагы предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр.

3. Административ һәм җинаять җәзасы билгеләнгән затларның мәҗбүри һәм төзәтү эшләрен яшәү урыны буенча оештырырга.

4. Җәза билгеләнгән затлар мәҗбүри һәм төзәтү эшләрен үти торган оешма җитәкчеләренә Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында һәм хезмәт законнарында каралган бурычлар йөкләнүен билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров